итүгә субсидия;

$РЗ_2$ – сайлап алу үткәрелгән елның II кварталында чыгымнарны тәэмин итүгә субсидия;

$РЗ_3$ – сайлап алу үткәрелгән елның III кварталында чыгымнарны тәэмин итүгә субсидия;

$РЗ_4$ – сайлап алу үткәрелгән елның IV кварталында чыгымнарны тәэмин итүгә субсидия.

Елның тиешле кварталында чыгымнарны тәэмин итүгә субсидия түбәндәге формула буенча исәпләнә:

$$РЗ_{i=}(Роптр_i+Рсим_i+Ринф_i+Рхоз_i+Радм_i)\text{, биредә}$$

$i$=1,2,3;

РЗ – 3 айга субсидиянең гомуми күләме, сум;

РЗ1, РЗ2, РЗ3 – 1, 2 һәм 3 нче ай (тәртип буенча) өчен субсидия күләме, сум;

Роптр – сәламәтлеге ягыннан мөмкинлекләре чикле балаларны социальләштерү эшчәнлеген гамәлгә ашыруны тәэмин итүче хезмәткәрләрнең хезмәтләре өчен түләүгә һәм (яки) гражданлык-хокукый характердагы килешүләр төзелгән хезмәткәрләрнең хезмәтләре өчен түләүгә һәм (яки) түләүле хезмәтләр күрсәтү турында килешүләр төзелгән белгечләрнең хезмәтләре өчен түләүгә чыгымнар, сум/ай;

Рсим – сәламәтлеге ягыннан мөмкинлекләре чикле балаларны социальләштерү эшчәнлеген гамәлгә ашыру өчен файдаланыла торган, оешманың эшләвен тәэмин итү өчен кирәкле милекне карап тотуга чыгымнар, сум/ай;

Ринф – мәгълүмати материалларны эшләүне, төрле коммуникация каналлары аша урнаштыруны һәм таратуны да кертеп, халыкка сәламәтлеге ягыннан мөмкинлекләре чикле балаларны социальләштерү эшчәнлеге турында мәгълүмат җиткерү белән бәйле чыгымнар, сум/ай;

Рхоз – сәламәтлеге ягыннан мөмкинлекләре чикле балаларны социальләштерү эшчәнлеге алып барыла торган биналарны агымдагы ремонтлау, санитар эшкәртү һәм җыештыру чыгымнарын үз эченә алган хуҗалык ихтыяҗлары белән бәйле чыгымнар, сум/ай;

Радм – документлар әйләнешен алып баруны, хисап әзерләүне һәм тапшыруны, консультацияләр бирүне һәм законнар үтәлешен тәэмин итә торган башка хезмәт күрсәтүләрне дә кертеп, оешма эшчәнлегенә административ, бухгалтерлык һәм юридик ярдәм күрсәтү белән бәйле чыгымнар, сум/ай.

